**5 нче сыйныф**

**Татар әдәбиятыннан тест**

**Габдулла Тукайның «Су анасы» әкият-поэмасы**

**1. Габдулла Тукай кайчан һәм кайда туган?**

а) 1886 нчы елда Арча районы Кушлавыч авылында;

ә) 1883 нче елда Арча районы Кырлай авылында;

б) 1880 нче елда Арча районы Өчиле авылында.

**2. Габдулла ничә яшьтә ятим кала?**

а) алты айлык вакытында — әнисе, өч яшендә әтисе үлә:

ә) алты айлык вакытында — әтисе, өч яшендә әнисе үлә:

б) алты айлык вакытында әнисе дә, әтисе дә үлә.

**3. 1907 нче елда Казанга кайтканчы, аңа кайсы җирләрдә булырга туры килә?**

а) Өчиле, Кырлай;

ә) Өчиле, Кырлай, Жаек;

б) Сасна, Өчиле, Казан, Кырлай, Жаек.

**4. Үзе исән чакта шагыйрьнең ничә китабы басылып чыга?**

а) уналты;

ә) утыз дүрт;

б) илле.

**5.«Су анасы» әсәре ничәнче елда язылган?**

а) 1907 нче елда;

ә) 1908 нче елда;

б) 1909 нчы елда.

**6.«Су анасы» әсәренә нигезләнеп язылган балет ничек дип атала?**

а) «Су анасы»;

ә) «Су анасы һәм малай»;

б) «Алтын тарак».

**7.Бу балетка музыканы кем язган?**

а) Нәҗип Җиһанов;

ә) Әнвәр Бакиров;

б) Заһид Хәбибуллин.

**8.«Тукаев — татар тарихында мәңге онытылмаслык исем!» фикерен, кем әйткән?**

а) Җамал Вәлиди;

ә) Резеда Ганиева;

б) Сибгат Хәким.

**9.Апуш Кырлай авылында ничә ел яши?**

а) 7 елга якын;

ә) 5 елга якын;

б) 3 елга якын.

**10.Кырлайда Габдулла Тукайга багышланган әдәби мемориаль музей комплексы ничәнче елда оештырылган?**

а) 1960 нчы елда;

ә) 1971 нче елда;

б) 1976 нчы елда.

## Ачкыч

1. **А**
2. **Ә**
3. **Б**
4. **Ә**
5. **Ә**
6. **Б**
7. **Ә**
8. **А**
9. **Б**
10. **А**

# Бәяләү

**9-10 балл – “5”ле**

**7-8 балл – “4”ле**

**5-6 балл – “3”ле**